ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү турында» 479-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары М.Г. Әхмәтов, Д.Р. Барыев, А.Р. Зарипов, С.М. Захарова, Ю.З. Камалтынов, Л.Н. Маврина, Х.Г. Миргалимов, А.А. Михеев, А.Р. Нәбиева, Р.Р. Нигъмәтуллин, Л.Н. Рыбакова, М.Х. Сәлахов, Э.С. Шәрәфиев тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү турында» 479-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Әлеге закон проектына төзәтмәләр 2023 елның 27 октябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты 2023 елның 1 декабренә кадәр әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2023 елның 19 октябре
№ 2190-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
М.Г. Әхмәтов, Д.Р. Барыев,
А.Р. Зарипов, С.М. Захарова,
Ю.З. Камалтынов, Л.Н. Маврина,
Х.Г. Миргалимов, А.А. Михеев,
А.Р. Нәбиева, Р.Р. Нигъмәтуллин,
Л.Н. Рыбакова, М.Х. Сәлахов,
Э.С. Шәрәфиев тарафыннан кертелә

# Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү турында

## Татарстан Республикасы Законы

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

1. Әлеге Закон Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү (алга таба – патриотик тәрбия бирү) өлкәсендә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала, патриотик тәрбиянең максатын, принципларын һәм бурычларын билгели.

2. Патриотик тәрбия турында Татарстан Республикасы законнары Россия Федерациясе Конституциясенең, Татарстан Республикасы Конституциясенең, федераль законнарның, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларының тиешле нигезләмәләренә таяна һәм әлеге Законнан, Татарстан Республикасының башка законнарыннан һәм алар нигезендә кабул ителә торган Татарстан Республикасы норматив хокукый актларыннан гыйбарәт.

2 статья. **Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр**

1. Әлеге Закон максатларында патриотик тәрбия дигәндә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, гражданнарга патриотик, шул исәптән хәрби-патриотик тәрбия бирү өлкәсендә эшчәнлек алып баручы коммерциягә карамаган социаль юнәлешле оешмаларның (алга таба – коммерциягә карамаган оешмалар) һәм башка патриотик тәрбия субъектларының гражданнарда патриотик аң, Ватанга тугрылык, Туган илне яклау өчен гражданлык бурычын һәм конституциячел йөкләмәләрне үтәргә әзерлек, Ватан тарихына ихтирам формалаштыру буенча максатчан юнәлешле эшчәнлегә аңлашыла.

2. Әлеге Законда кулланыла торган башка төшенчәләр федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән мәгънәләрендә кулланыла.

3 статья. **Патриотик тәрбиянең максаты, принциплары һәм**

**бурычлары**

1. Патриотик тәрбиянең төп максаты гражданнарда рухи-әхлакый һәм социаль кыйммәтләр, гражданлык формалаштырудан, конституциячел һәм хәрби бурычка тугрылык, җаваплылык һәм дисциплина тәрбияләүдән гыйбарәт.

2. Патриотик тәрбиянең принциплары:

1) гражданнар белән адреслы эш;

2) системалылык, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының патриотик тәрбия субъектлары, шул исәптән коммерциягә карамаган оешмалар белән үзара эшчәнлеген оештыру;

3) патриотик тәрбия өлкәсендә эшчәнлекне оештырганда гражданнарның милли, этномәдәни, конфессиональ үзенчәлекләрен исәпкә алу;

4) гражданнарга патриотик тәрбия бирүдә өзлексезлек һәм дәвамчанлык;

5) патриотик тәрбиягә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләүдә ачыклык һәм бәйсезлек;

6) Россия җәмгыятенең нигезе буларак, гаиләгә тиешле мөнәсәбәт булдыру.

3. Патриотик тәрбиянең төп бурычлары:

1) гражданнарга Россия Федерациясе Конституциясен, Татарстан Республикасы Конституциясен хөрмәт итү, законнарны үтәү рухында тәрбия бирү;

2) гражданнарда Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының мәдәни һәм тарихи үткәненә һәм гореф-гадәтләренә хөрмәт, Ватанга хезмәт итәргә, аны якларга, гражданлык бурычын, һөнәри һәм хәрби бурычны намус белән үтәргә әзерлек формалаштыру;

3) гражданнарда Россия Федерациясе дәүләт символларына, Татарстан Республикасы дәүләт символларына карата горурлану һәм ихтирам хисләре уяту;

4) патриотик тәрбия системасын үстерү, дәүләт хезмәтенең абруен арттыру, гражданнарны Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәткә әзерләүне камилләштерү;

5) ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлеген үстерү;

6) гражданнарда рухи-әхлакый үсешкә ихтыяҗ һәм өлкән буынга ихтирамлы мөнәсәбәт булдыру, буыннар арасында элемтәләрне тәэмин итү, өлкәннәр һәм якын кешеләр турында кайгырту, гаилә институтын ныгыту һәм традицион гаилә кыйммәтләрен саклап калу;

7) халыклар арасында дуслык багланышларын үстерү, милләтара һәм конфессияара татулыкны тәэмин итү, экстремизм күренешләренә каршы тору өчен шартлар тудыру.

4 статья. **Патриотик тәрбия өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәте**

1. Патриотик тәрбия өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәте Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан җирле үзидарә органнары һәм патриотик тәрбия субъектлары белән үзара хезмәттәшлектә гамәлгә ашырыла торган патриотик тәрбиягә юнәлдерелгән чаралар җыелмасыннан

гыйбарәт.

2. Патриотик тәрбия өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру түбәндәге рәвешләрдә гамәлгә ашырыла:

1) патриотик тәрбия өлкәсендә норматив хокукый җайга салу;

2) патриотик тәрбия системасын фәнни һәм методик яктан тәэмин итү, патриотик тәрбия бирү эшенең иң уңышлы һәм перспективалы рәвешләрен һәм ысулларын тарату;

3) патриотик тәрбия өлкәсендә ведомствоара эшчәнлек һәм дәүләт-җәмгыять партнерлыгын үстерү;

4) балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирүне оештыру һәм үткәрү, аларның Ватанга хезмәт итүгә мотивациясен, Ватан тарихын өйрәнүгә кызыксынуын арттыру буенча программалар, методикалар эшләү һәм кертү;

5) патриотик тәрбия өлкәсендә белгечләр әзерләү;

6) патриотик тәрбияне мәгълүмати тәэмин итү;

7) тарихи, туган якны өйрәнү буенча һәм мемориаль музейлар булдыру һәм аларны саклау, һәйкәлләр, обелисклар, стеллалар, хәрби дан көннәрен һәм Россия Федерациясенең истәлекле даталарын, Татарстан Республикасының истәлекле даталарын мәңгеләштерүче башка мемориаль корылмалар, объектлар урнаштыру һәм аларны төзекләндерү, күргәзмәләр оештыру, хәрби дан урыннарында мемориаль билгеләр кую;

8) Татарстан Республикасының тарихи урыннары буйлап туристик маршрутлар эшләү;

9) хәрби хезмәткә чакырылу яшенә җитеп килгән һәм шул яшькә җиткән гражданнарга хәрби хезмәткә әзерлек узу өчен шартлар булдыру;

10) мәгариф оешмаларының ветераннар оешмалары, сугышчан дан музейлары, шулай ук сугыш, хәрби хәрәкәтләр, хәрби хезмәт ветераннары белән үзара эшчәнлек системасын оештыру һәм үстерү;

11) патриотик юнәлештәге әсәрләр иҗат итүдә сәнгать һәм әдәбият әһелләренә ярдәм күрсәтү;

12) хәрби дан көннәренә һәм Россия Федерациясенең истәлекле даталарына, Татарстан Республикасының истәлекле даталарына багышланган тантаналы һәм истәлекле чаралар оештыру һәм уздыру;

13) патриотик тәрбия өлкәсендә иҗтимагый проектларга ярдәм итү.

5 статья. **Патриотик тәрбия субъектлары**

Патриотик тәрбия субъектлары түбәндәгеләр:

1) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм алар карамагындагы оешмалар;

2) җирле үзидарә органнары һәм алар карамагындагы оешмалар;

3) мәгариф һәм фән оешмалары;

4) дәүләт һәм муниципаль мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмалары;

5) яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт өлкәсендәге дәүләт һәм муниципаль оешмалар;

6) коммерциягә карамаган оешмалар;

7) иҗтимагый-дәүләти оешмалар, ветераннар оешмалары, эзтабарлар берләшмәләре һәм патриотик юнәлештәге башка иҗтимагый берләшмәләр;

8) дәүләт һәм муниципаль массакүләм мәгълүмат чаралары;

9) патриотик тәрбия үзәкләре;

10) абруе, патриотизмы һәм гражданлык һәм һөнәри бурычына тугрылыгы күркәм этәргеч һәм охшар өчен үрнәк булган Россия Федерациясе гражданнары.

6 статья. **Патриотик тәрбия өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) патриотик тәрбия өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне законнар белән җайга салу;

2) патриотик тәрбия өлкәсендә Татарстан Республикасы законнарын үтәүне һәм гамәлгә ашыруны тикшереп тору;

3) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

2. Татарстан Республикасы Рәисе вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) патриотик тәрбия өлкәсендә норматив хокукый актлар чыгару;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм патриотик тәрбиянең башка субъектлары белән эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итү;

3) Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү буенча координация советы (алга таба – Координация советы) төзү, Координация советы һәм аның составы турындагы нигезләмәне раслау;

4) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) патриотик тәрбия өлкәсендә норматив хокукый актлар чыгару;

2) патриотик тәрбия өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләрен билгеләү;

3) патриотик тәрбия өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт программаларын раслау;

4) патриотик тәрбия өлкәсендә җирле үзидарә органнарына методик ярдәм итүне оештыру;

5) патриотик тәрбия өлкәсендә коммерциягә карамаган оешмаларга булышу һәм ярдәм күрсәтү;

6) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

4. Мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) мәгариф оешмаларында укучыларга патриотик тәрбия бирүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру;

2) патриотик тәрбия өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча патриотик юнәлештәге иҗтимагый берләшмәләр белән үзара эшчәнлек;

3) укучыларда патриотик аң формалаштыруга юнәлдерелгән чаралар оештыру һәм уздыру;

4) укучылар арасында патриотик тәрбия буенча олимпиадалар һәм конкурслар оештыру һәм уздыру;

5) гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның хәрби хезмәт нигезләре буенча башлангыч белемнәр алуын тәэмин итү;

6) урта гомуми белем бирү яисә урта һөнәри белем бирү уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында укучыларны хәрби хезмәт нигезләренә әзерләү үткәрүне оештыру;

7) мәгариф оешмаларында туган якны өйрәнү хәрәкәте, Татарстан Республикасының тарихи-мәдәни мирасын өйрәнү буенча тикшеренү, мәдәни-агарту эшләре үсешенә ярдәм итү;

8) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

5. Яшьләр сәясәте өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) яшьләрнең патриотик, сәяси һәм гражданлык активлыгы, җитлегү дәрәҗәсен күтәрү;

2) гражданлык-патриотик тәрбиянең яшьләрдә рухи кыйммәтләр формалаштырудагы ролен көчәйтү;

3) яшьләргә патриотик тәрбия бирү системасын үстерү, яшьләр мохитендә милли үзаңны һәм толерантлыкны арттыру;

4) Татарстан Республикасында ихтыярыйлык (волонтерлык) хәрәкәтен үстерүгә ярдәм итү;

5) патриотик юнәлештәге чаралар оештыру һәм уздыру;

6) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

6. Мәдәният, сәнгать, кинематография өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыручы һәм мөнәсәбәтләрне җайга салучы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы тарихи вакыйгаларына һәм истәлекле даталарына багышланган чаралар үткәрүне оештыру;

2) патриотик тәрбия өлкәсендә фестивальләр, конкурслар, күргәзмәләр, кинофестивальләр, иҗади семинарлар, тамашачылар белән тематик очрашулар һәм башка чаралар оештыру, шул исәптән аларны уздыру тәртибен билгеләү;

3) патриотик тәрбия өлкәсендә Россиядәге һәм халыкара күргәзмәләрдә, конференцияләрдә, фестивальләрдә һәм конкурсларда катнашу, патриотик темага күргәзмәләр оештыру;

4) Ватанны яклаучы (яклаучылар) һәм аның (аларның) кылган батырлыгы истәлеген мәңгеләштерүгә багышланган иң яхшы музейга (музей экспозициясенә) конкурс үткәрү;

5) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

7. Физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт идарәсен һәм эшчәнлекне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы

вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Татарстан Республикасында барлык яшь төркемнәрендәге халыкның физик яктан әзерлек дәрәҗәсен арттыру максатларында физкультура-савыктыру спорт чаралары оештыру;

2) хәрби-гамәли спорт төрләрен пропагандалау;

3) Татарстан Республикасында барлык яшь төркемнәрендәге халык, шул исәптән хәрби хезмәткә чакырылу яшенә җитеп килгән һәм шул яшькә җиткән гражданнар, мәгариф оешмаларында укучылар һәм өлкән яшьтәге гражданнар өчен «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) бөтенроссия физкультура-спорт комплексын тапшыруны оештыру;

4) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

8. Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә дәүләт идарәсе мәсьәләләре буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) патриотик тәрбия өлкәсендәге чараларны массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны оештыру;

2) патриотизм формалаштыруга ярдәм итә торган китаплар һәм басма продукция нәшер итүне һәм таратуны оештыру;

3) патриотик темага журналистлар конкурслары, иҗади конкурслар оештыру һәм үткәрү;

4) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

9. Туризм өлкәсендә дәүләт идарәсе функцияләрен башкаручы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Татарстан Республикасының тарихи урыннары буйлап туристик маршрутлар эшләүдә ярдәм күрсәтү;

2) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

### 7 статья. **Патриотик тәрбиядә җирле үзидарә органнарының катнашуы**

1. Җирле үзидарә органнары федераль законнарда билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә патриотик тәрбия бирү эшчәнлегендә катнашырга хокуклы.

2. Җирле үзидарә органнары патриотик тәрбия өлкәсендәге чараларны үз эченә алган муниципаль программалар расларга хокуклы.

### 8 статья. **Координация советы**

1. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының, башка дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының, шулай ук патриотик тәрбиянең башка субъектларының үзара эшчәнлеген камилләштерү максатларында Координация советы төзелә.

2. Координация советы Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан төзелә һәм консультация-киңәшмә орган булып тора.

3. Координация советы составына Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, коммерциягә карамаган оешмалар вәкилләре керә. Координация советы составына, кирәк булганда, патриотик тәрбиянең башка субъектларыннан да вәкилләр кертелергә мөмкин.

4. Координация советы ел саен Татарстан Республикасы Рәисенә Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра.

9 статья. **Патриотик тәрбияне пропагандалауга юнәлдерелгән чараларда гражданнарның катнашуы**

Патриотик тәрбия, хәрби хезмәтнең абруен күтәрү, шулай ук Ватанны саклауны пропагандалау чараларын гамәлгә ашыру кысаларында гражданнар түбәндәге чараларда катнашырга хокуклы:

1) хәрби каберлекләрне, Ватанны саклаганда һәлак булганнар күмелгән урыннарны саклауда һәм төзекләндерүдә, кабер ташлары, һәйкәлләр, стеллалар, обелисклар, һәлак булганнарның истәлеген мәңгеләштерүче башка мемориаль корылмалар һәм объектлар урнаштыруда;

2) Ватанны саклаганда һәлак булганнар батырлыгына тарихи яктан бәйле булган аерым территорияләрне саклауда һәм төзекләндерүдә;

3) Ватанны саклаганда һәлак булганнарны һәм хәбәрсез югалганнарны эзләүдә, аларның исемнәрен ачыклауда;

4) Ватанны саклаганда һәлак булганнар турындагы материалларны массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуда, аларның батырлыгына багышланган истәлекле күргәзмәләр оештыруда һәм уздыруда;

5) федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка чараларда.

10 статья. **Патриотик тәрбиядә коммерциягә карамаган оешмаларның катнашуы**

1. Татарстан Республикасында коммерциягә карамаган оешмалар түбәндәгеләргә хокуклы:

1) федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә патриотик тәрбия өлкәсендә чаралар оештырырга һәм уздырырга;

3) патриотик тәрбиядә федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка рәвешләрдә катнашырга.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары коммерциягә карамаган оешмаларга патриотик тәрбиянең мәдәни, рухи һәм әхлакый нигезләрен ныгытуда түбәндәгечә ярдәм итә:

1) Татарстан Республикасы дәүләт программалары кысаларында патриотик тәрбия чараларында катнашуга җәлеп итү юлы белән;

2) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка рәвешләрдә.

11 статья. **Патриотик тәрбия өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү**

Патриотик тәрбия өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында бу максатларга каралган акчалар кысаларында Татарстан Республикасы бюджеты акчалары, шулай ук федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында тыелмаган башка чыганаклар исәбенә гамәлгә ашырыла.

12 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү турында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

Хәзерге вакытта патриотик тәрбия өлкәсендә хокукый җайга салу федераль дәрәҗәдә төрле закон актлары һәм алар нигезендә чыгарылган актлар белән гамәлгә ашырыла. «Россия балалар һәм яшьләр хәрәкәте турында» 2022 елның 14 июлендәге 261-ФЗ номерлы Федераль законда әлеге хәрәкәтнең максатлары билгеләнде, алар яшьләрне тәрбияләү процессын гражданлык җәмгыятенең һәм дәүләтнең барлык институтлары катнашында камилләштерүгә юнәлдерелгән. Россия Федерациясенең кайбер субъектларында бу өлкәдә хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган законнар да кабул ителде.

Татарстан Республикасында яшьләрне патриотик тәрбияләү системасын үстерү һәм камилләштерү, дәүләт сәясәтенә карата рәсми кабул ителгән карашлар җыелмасын чагылдыра торган системалы алым эшләү һәм Татарстан Республикасы яшьләрен патриотик тәрбияләү өлкәсендәге эшчәнлекнең төп юнәлешләрен билгеләү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 16 сентябрендәге 666 номерлы карары белән Татарстан Республикасы балаларына һәм яшьләренә патриотик тәрбия бирү концепциясе расланды.

Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарының һәм Татарстан Республикасы иҗтимагый берләшмәләренең яшьләрне патриотик тәрбияләү буенча үзара хезмәттәшлеген камилләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 12 февралендәге 77 номерлы карары белән патриотик тәрбия буенча Татарстан Республикасы координация советы төзелде.

Министрлар Кабинетының 2019 елның 5 мартындагы 158 номерлы карары белән расланган «2019-2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасының «2019-2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләргә патриотик тәрбия бирү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру кысасында Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы тарафыннан министрлыклар һәм ведомстволар, муниципалитетлар, иҗтимагый берләшмәләр белән берлектә яшьләргә патриотик тәрбия бирү эшчәнлеге башкарыла. Ярдәмче программаның төп максатлары – республикада иҗтимагый һәм икътисадый тотрыклылыкны тәэмин итә торган патриотик тәрбия системасын үстерү һәм модернизацияләү, Татарстан Республикасы балаларында һәм яшьләрендә граждан тәңгәллеге, югары патриотик аң, Ватанга тугрылык формалаштыру, конституциячел бурычларны, толерантлык, милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр культурасын үтәүгә әзерлек тәрбияләү.

Тупланган эш тәҗрибәсен саклап калуның мөһимлеген, Татарстан Республикасында төзелгән патриотик тәрбия системасын ныгытуның һәм алга таба үстерүнең актуальлеген исәпкә алып, бу мәсьәләне законнар белән комплекслы җайга салу зарурлыгы килеп туды.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе белән төзелгән эшче төркем тарафыннан Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик

тәрбия бирү өлкәсендә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне законнар белән җайга салу максатларында «Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү турында» Татарстан Республикасы законы проекты эшләнде.

Закон проекты гражданнарга патриотик тәрбия бирү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәтен билгели, аның максатын, принципларын, бурычларын, шулай ук патриотик тәрбия субъектларын, хокукый һәм оештыру нигезләрен билгели.

Закон проектында гражданнарга патриотик тәрбия бирү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләр бүленә. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының вәкаләтләре билгеләнә.

Закон проектының аерым статьялары Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү буенча координация советына, гражданнарның һәм коммерциягә карамаган оешмаларның патриотик тәрбиядә катнашуына багышлана. Закон проектында җирле үзидарә органнары гражданнарга патриотик тәрбия бирү эшчәнлегендә катнашырга һәм патриотик тәрбия өлкәсендә муниципаль программалар расларга хокуклы дип билгеләнә.

Закон проекты Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү өлкәсендә бердәм алымнар булдырырга һәм бу өлкәдәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу механизмын камилләштерергә мөмкинлек бирәчәк.

**«Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарының үз көчләрен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә яңаларын кабул итү таләп ителми.

«Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә:

Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү буенча координация советы һәм аның составы турындагы нигезләмәне раслау хакында Татарстан Республикасы Рәисе акты чыгару;

«Патриотик тәрбия бирү буенча Татарстан Республикасы координация советы төзү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 12 февралендәге 77 номерлы карарын һәм аңа үзгәрешләр кертү актларын үз көчен югалткан дип тану;

«Татарстан Республикасы балаларына һәм яшьләренә патриотик тәрбия бирү концепциясен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 16 сентябрендәге 666 номерлы карарына үзгәрешләр кертү таләп ителә.

**«Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү турында» Татарстан Республикасы законы проектын финанс-икътисадый нигезләү**

«Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бир турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән өстәмә чыгымнарны таләп итми.

Финанслау күләмнәре Министрлар Кабинетының 2019 елның 5 мартындагы 158 номерлы карары белән расланган «2019-2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасының «2019-2025 елларга Татарстан Республикасы яшьләренә патриотик тәрбия бирү» ярдәмче программасында билгеләнгән (алга таба – Ярдәмче программа). 2023 елга һәм 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетында Ярдәмче программаны гамәлгә ашыруга ел саен 10 050,0 мең сум күләмендә акча каралган.

Ярдәмче программаның төп максатлары – республикада иҗтимагый һәм икътисадый тотрыклылыкны тәэмин итә торган патриотик тәрбия системасын үстерү һәм модернизацияләү, Татарстан Республикасы балаларында граждан тәңгәллеге, югары патриотик аң, Ватанга тугрылык формалаштыру, конституциячел йөкләмәләрне, толерантлык, милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр культурасын үтәүгә әзерлек формалаштыру.

Ярдәмче программа чараларын башкаручылар – Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгы.

Гамәлдәге Ярдәмче программа кысаларында «Аҗаган» хәрби-спорт уены, «Мин – Россия гражданы!» акциясе, җәйге хәрби-патриотик лагерьлар, «Җиңү» хәрби-спорт уеннарының республика этабы, гомуми белем бирү оешмалары укучылары өчен хәрби-укыту җыеннары, кадетлар арасында спортның хәрби-гамәли төрләре буенча «Татарстан Республикасы ветераннар берлеге» республика иҗтимагый оешмасы күчмә кубогына республика спартакиадасы, Җиңү Диктанты һәм башкалар уздырыла. Әлеге чараларга өстәмә финанслау таләп ителми.

Ярдәмче программа чараларын башкаручылар исемлегеннән тыш, закон проектында Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына һәм Татарстан Республикасы туризм буенча дәүләт комитетына гражданнарга патриотик тәрбия бирү өлкәсендә вәкаләтләр билгеләнә. Әлеге вәкаләтләрне гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән өстәмә финанслауны таләп итми һәм Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 5 мартындагы 159 номерлы карары белән расланган «2019 – 2025 елларга Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерү» дәүләт программасының «2019 – 2025 елларга Татарстан Республикасында физик культураны һәм массакүләм спортны үстерү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру кысаларында физкультура-савыктыру спорт чаралары

үткәрү өчен каралган, шул исәптән Татарстан Республикасы халкының төрле яшь төркемнәре арасында «Хезмәткә һәм оборонага әзер» бөтенроссия физкультура-спорт комплексын популярлаштыруга һәм гамәлгә кертүгә юнәлдерелгән акчалар исәбенә һәм Татарстан Республикасы Туризм буенча дәүләт комитеты тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 21 декабрендәге 522 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында туризмны һәм кунакчыллыкны үстерү» дәүләт программасында каралган акчалары кысаларында гамәлгә ашырылачак.

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының аерым вәкаләтләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 16 декабрендәге 997 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү» дәүләт программасының төрле ярдәмче программаларын гамәлгә ашыру кысаларында музейлар тарафыннан мәдәни һәм фәнни-агарту, белем бирү эшчәнлеген башкару, китапханәләрнең китап укуны популярлаштыру буенча мәдәни-агарту эшчәнлеген киңәйтү, мәктәп укучыларын рухи-әхлакый үстерү һәм патриотик тәрбияләү өчен мәдәни-агарту программаларын гамәлгә ашыру өчен каралган чаралар чикләрендә гамәлгә ашырылачак.

Гражданлык-патриотик тәрбия бирү программаларын гамәлгә ашыру, балалар хәрәкәтен үстерү шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 22 февралендәге 110 номерлы карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасы кысаларында каралган.

Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының закон проекты белән билгеләнгән аерым вәкаләтләре аларның төп эшчәнлеге кысаларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының расланган нигезләмәләре нигезендә гамәлгә ашырылачак. Мәсәлән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы мәсьәләләре» турында 2018 елның 11 июлендәге 563 номерлы карары нигезендә ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлеге өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга салу Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы җаваплы булган вазыйфаларның берсе булып тора.